КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 июнь г.Казань № 490

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче, 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы, 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2015 – 2020 елларда» сүзләрен «2015 – 2025 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулда «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2015 – 2020 елларда» сүзләрен «2015 – 2025 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2015 – 2020 елларда инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклау белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2015 – 2020 елларда» сүзләрен «2015 – 2025 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2015 – 2020 елларда» сүзләрен «2015 – 2025 елларда» сүзләренә, «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп кору, бетерү процессында тормыйлар, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;»;

4 пунктта:

беренче абзацта «кушымта нигезендә» сүзләрен «1 нче кушымта нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «предприятие» сүзен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүченең үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган белешмә;»;

8 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән һәм эш бирүче тарафыннан тапшырылган гаризада һәм документларда булган мәгълүматның дөрес булмавы;»;

9 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәсенең әһәмияте, эш белән тәэмин итү үзәгенең өстәмә хисаплылык срокларын һәм формасын билгеләү хокукы, субсидия алучының субсидияне кире кайтару очраклары, тәртибе, сроклары, эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерү гамәлгә ашыру, субсидия алучының эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, субсидия алучының әлеге тәртипне һәм төзелә торган шартнамәнең шартларын үтәү турындагы нигезләмәне үтәүләренә, Шартнамәне бозган өчен җаваплылыкны тикшерүенә ризалыгы карала.»;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктның беренче абзацында «предприятие» сүзен «эш бирүче» сүзенә алмаштырырга;

13 пунктта «предприятие» сүзен «эш бирүче» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $13^1$– $13^4$ пунктлар өстәргә:

«$13^1$. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып эш бирүченең инвалидлар өчен субсидия бирү чоры дәвамында эш бирүченең гаризасында күрсәтелгән эш урыннарын саклап калу тора.

$13^2$. Эш бирүче субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисапны эш белән тәэмин итү үзәгенә әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча тапшыра.

$13^{3}$. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка эш бирүчегә субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башкарылган чыгымнар һәм эш бирүче тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыралар.

$13^{4}$. Министрлыкка тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.»;

14 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия суммасының 1 проценты күләмендә – килешүдә каралган субсидия бирү нәтиҗәсенең әһәмиятенә ирешмәгән өчен.»;

15 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Шул ук вакытта субсидия алучы, акчаны кире кайтарудан тыш, субсидия алганнан соң киләсе көннән башлап аны кире кайтарган көнне дә кертеп, кичектерелгән һәр көн өчен бурыч суммасыннан 0,03 процент күләмендә пеня түли.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан эш бирүчеләргә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерә.

Эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы эш бирүчеләр тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.»;

17 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

Тәртипкә кушымтаны 1 нче кушымта дип санарга һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Тәртипкә 2 нче кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин